ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от «11» января 2023 г.** **№ 3**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясе буенча гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багаж ташуны оештыру тәртибен раслау турында» Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 22 апрелендәге 475 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Арча муниципаль районы халкының пассажирлар ташуга һәм транспорт хезмәтенә булган ихтыяҗларын канәгатьләндерүне тәэмин итү максатыннан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багажны ташуны оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»" 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багаж ташуны оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законны гамәлгә ашыру хакында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясе буенча гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багаж ташуны оештыру тәртибен раслау турында» Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 22 апрелендәге 475 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясе буенча гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм

багаж ташуны оештыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Транспортта муниципаль маршрут буенча гамәлгә ашырыла торган даими пассажирлар ташу төрен үзгәртү, әгәр әлеге карар транспортны планлаштыру документында яисә халыкка даими транспорт хезмәте күрсәтүнең региональ комплекслы планында каралган булса, рөхсәт ителә»;

2) 23 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23. Җайга салынулы тарифлар буенча пассажирларны даими ташу түбәндәгеләрне гамәлгә ашыру аша башкарыла:

1) федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы яисә җирле үзидарәнең вәкаләтле органы яки дәүләт яисә муниципаль контрактның бүтән дәүләт яисә муниципаль заказчысы тарафыннан дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бәяләмәләр;

2) пассажирларны һәм багажны даими ташу һәм аларның хәрәкәтен технологик яктан тәэмин итүче объектларны эксплуатацияләү өчен шәһәр җир өсте электр транспорты (трамвайлар, троллейбуслар), батареядан электр энергиясе алып хәрәкәтләнә торган автобуслар куллануны күздә тоткан муниципаль-шәхси партнерлык турында килешүләр, тышкы чыганактан тулылана торган (электробуслар) куллануны күздә тоткан концессион килешүләр турында Россия Федерациясе законнары, дәүләт-хосусый партнерлык турында Россия Федерациясе законнары, концессион килешүнең муниципаль-шәхси партнерлыгы турында килешүләр, дәүләт-хосусый партнерлык турында килешүләр бәяләмәләре - даими транспортны планлаштыру документында яки халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең региональ комплекслы планында каралган очракта.»;

3) 25 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«25. Дәүләт яки муниципаль заказчы, концедент, гавами партнер дәүләт яки муниципаль контракт, дәүләт-шәхси партнерлык турында килешү яисә муниципаль-шәхси партнерлык турында килешү, даими транспорт маршруты картасы концессион килешүе төзелгән срокка даими пассажирлар ташу маршрутлары реестрына кертелгән һәм аның турында Федераль законның 26 статьясындагы 1 өлешенең 13 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне дәүләт яки муниципаль контракт, дәүләт-шәхси партнерлык турында килешү яисә муниципаль-шәхси партнерлык турында килешү төзегән затка тапшыра»;

4) 32 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«32. Пассажирларны даими ташу муниципаль маршруты, даими маршрут буенча муниципальара маршрут һәм тиешле маршрут картасы буенча пассажирлар ташуны гамәлгә ашыру турындагы таныклык Федераль законда билгеләнгән тәртиптә даими маршрут буенча пассажирлар ташу хокукына ачык конкурс нәтиҗәләре буенча бирелә.»;

5) 40 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«40. Юридик затка, шәхси эшкуарга яисә гади ширкәт килешүендә катнашучыларның берсенә бирелгән даими ташу маршруты картасы аның гамәлдә булу срогы озайтылган очракта, транспорт чарасының характеристикалары яки классы билгеләнгән тәртиптә үзгәргән очракта, юридик затны үзгәртү рәвешендә үзгәртеп кору, аның исеме, урнашкан урыны адресы үзгәрү, шулай ук шәхси

эшкуарның яшәү урыны, фамилиясе һәм (яки) исеме, һәм (яки) атасының исеме үзгәргән очракта, мондый килешүдә катнашучыларның берсенең үлеме белән бәйле рәвештә гади ширкәтлек килешүендә катнашучылар составы үзгәргән очракта, яңадан рәсмиләштерелергә тиеш,.»;

6) 47 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«47. Даими пассажирлар ташу муниципаль маршруты карталарының гамәлдә булуы әлеге маршрут буенча пассажирлар ташуны гамәлгә ашыру турындагы таныклыкның гамәлдә булуы тукталган көннән, ә даими ташулар муниципаль контракт нигезендә яки концессион килешү яисә дәүләт-хосусый партнерлык турындагы килешү, яисә муниципаль-шәхси партнерлык турындагы килешү нигезендә башкарылса, әлеге контракт яисә концессион килешү, дәүләт-шәхси партнерлык яки муниципаль-шәхси партнерлык килешүе тукталган көннән туктатыла».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары И.Ә. Галимуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р. М. Гатиятов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ИНН
1609009516